**Р. К. Шәехова**



*Мәктәпкәчә яшьтәгеләр әлифбасы:*

# авазларны уйнатып

**Эш дәфтәре**

**1 нче кисәк**

Мәктәпкә әзерлек төркемендә тәрбияләнүче балалар өчен

Казан

ХӘТЕР

2011

УДК 512.145
ББК 81.2Тат
Ш11

Рецензентлар:
**М. Г. Мозаффарова** —
*ТР Мәгарифне үстерү институтының мәгарифтә милли проблемалар лабораториясе мөдире, педагогика фәннәре кандидаты*
**Г. Х. Кәримова** —
*Казан шәһәре 50 нче балалар бакчасының югары квалификация категорияле татар теленә өйрәтү тәрбиячесе*

Тышлык рәссамы ***Юлия Щетинкина***
Рәссамы ***Влада Семенова***

**Шәехова, Р.К.**
Ш11 Мәктәпкәчә яшьтәгеләр әлифбасы: авазларны уйнатып : эш дәфтәре : 1 нче кисәк : мәктәпкә әзерлек төркемендә тәрбияләнүче балалар өчен / **М. С. Нургалиева** тәрҗ.– Казан : Татарстан Республикасы «ХӘТЕР» нәшрияты, 2011.– 96 б.: рәс. б-н.
ISBN 978-5-94113-364-2

Бу ярдәмлек мәктәпкә әзерлек төркемендәге балаларны уку-язу нигезләрен үзләштерүгә әзерләү буенча шөгыльләр системасыннан гыйбарәт.
1 нче эш дәфтәрендәге уенлы биремнәр балаларда татар телендәге калын һәм нечкә тартыкларны, сузык авазларны аеру, ишетелә торган сүзнең төзелеше белән кызыксыну сәләтләрен үстерүгә юнәлтелгән.
Эш дәфтәре мәктәпкә әзерлек төркемендәге балаларга, бу төркемнәрнең тәрбиячеләренә, ата-аналарга адреслана.

УДК 512.145
ББК 81.2Тат

ISBN 978-5-94113-364-2

© Татарстан Республикасы «ХӘТЕР» нәшрияты, 2011
© Шәехова Р. К., 2011

## Сәлам, дустым!

Тиздән, бик тиздән, син укучы булырсың!

Укучы – зур максатларга бара торган кеше.

Беренче сыйныф укучылары калын-калын китаплар гына укыйлар, күп итеп язалар, беркайчан да уйнамыйлар, шаярмыйлар дип уйлый күрмә тагын. Бу һич тә алай түгел! Мәктәп тормышы бик кызыклы, мавыктыргыч ул! Син укытучылар ярдәмендә бик күп файдалы һәм кызыклы әйберләр белерсең. Ә үзең укырга өйрәнгәч, кояш һәм ай, хайваннар һәм кошлар, әкиятләрдәге әйбәт һәм начар каһарманнар турында китаплардан укып белерсең.

Ә быел без синең белән тырышып мәктәпкә әзерләнербез. Мәктәптә яхшы укыр өчен укырга һәм язарга өйрәнергә тырышырбыз. Син сүзләр һәм авазлар белән уеннар уйнап, укуның кызыклы икәнен аңларсың. Тәрбияче апаларың сиңа һәрчак ярдәм итеп торыр.

Хәерле юл «Әлифба иле»нә, дустым! Сиңа зур уңышлар телим!

*Автор*


























**1.** Тәрбияче балаларга, көзге паркта йөргән кебек, бүлмә буйлап йөрергә һәм аяк астында яфраклар кыштырдавын искә төшерергә тәкъдим итә. Балалар белән бергә йөреп, «кыш-ш-штыр, кыш-ш-штыр, ш-ш-ш», ди, балаларда үзе артыннан **[ш]** авазын кабатлау теләге уята.

**2.** Балалар урыннарына утыралар һәм бирелгән рәсемнәрдән **[ш]** авазы кергән сүзләрне атыйлар, һәр сүзне «яфраклар кыштырдавы ишетелерлек» итеп, **[ш]** авазын аерып алып әйтәләр *кыш-ш-штыр, кош-ш-ш, ш-ш-шар, ш-ш-шарф.*

**3.** Балалар *пирожный, жираф* сүзләренең әйтелешен тыңлыйлар. Монда «яфраклар кыштырдавы» ишетелмәвен әйтеп бирәләр.

**Сүзләр белән эш:**

**[ш]** авазы кергән сүзләр: *шар, шарф, кишер, шалкан, кош, шикәр, чыршы;*
**[ш]** авазы кермәгән сүзләр: *пирожный, жираф.*

### Шарик каян шар тапкан

Шаян Шарик шар тапкан,
Шарик шарны шартлаткан.
Шарик шарга шаккаткан,
Шардай күзен шарлаткан.

*Роберт Миңнуллин*




**1.** Тәрбияче тел шомарткычны ике тапкыр укып чыга, аны кабатлап сөйләргә теләгән балаларны үз янына чакыра.

**2.** Тәрбияче, интонация белән **[ш]** авазын аерып алып, тел шомарткычны тагын бер тапкыр укып чыга. «Сез бу тел шомарткычта яфраклар кыштырдавын ишеттегезме?» — дип сорый.

Тәрбияче балаларга тел шомарткычны үзе белән бергә нәкъ шул рәвешчә кабатларга тәкъдим итә.

**3.** Балалар биремнәрендә «яфраклар кыштырдавы» **[ш]** авазы ишетелгән рәсемнәрне әйтеп чыгалар.





**4. «Кайтаваз» уены.**

Тәрбияче, **[ш]** авазы кергән сүзне әйтеп, тупны балага ыргыта. Бала, сүзне нәкъ шулай ук кабатлап, тупны кире кайтара. Уенның шарты: бала сүзне, **[ш]** авазын аерып алып, әйтеп бирергә тиеш. Әгәр дә бала уенның шартын мөстәкыйль рәвештә яки алып баручы ярдәме белән үтәсә, туп башка балага тапшырыла.

**Сүзләр белән эш:**

**[ш]** авазы кергән сүзләр: *каш, машина, оекбаш, шакмак, карандаш, (яшь) кеше;*

**[ш]** авазы кермәгән сүзләр: *аю, туңдырма, жираф.*



Илләр аша карлар ташып,
Выжылдыйбыз: — Выж-ж-ж!..
Юллар күрәп, көртләр өеп,
Ыжылдыйбыз: — Ыж-ж-ж!..

**1.** Тәрбияче шигъри табышмакны укып чыга, аның җавабын әйтергә куша. Кабатлап укып, балаларда табышмакны истә калдыру теләге уята.

**2.** Тәрбияче шигъри табышмакны тагын бер тапкыр сәнгатьле итеп, **[ж]** авазын интонация белән аерып алып укый.

Балаларга рәсемнәр буенча жил выжылдаган тавыш ишетелгән авазлы сүзләрне әйтеп бирергә тәкъдим итә. Һәр сүздә **[ж]** авазын интонация белән аерып күрсәтергә куша.


**3.** Балалар рәсемнәр буенча «яфраклар кыштырдавы» **[ш]** авазы ишетелгән сүзләрне атыйлар.













**4. «Кем күбрәк сүз әйтә?» уены.**

Балалар **[ж]** авазы кергән сүзләр уйлап әйтәләр. Дөрес җаваплар өчен фишкалар бирелә. Күбрәк фишкалар җыйган бала җиңүче итеп танyла.

**Сүзләр белән эш:**

**[ш]:** *кашык, көнбагыш, башлык, кош, груша;*
**[ж]:** *жилет, журнал, жираф, пирожный.*



**1.** Балалар тәрбияче белән бергәләп бүлмә буйлап коңгызлар булып очып йөриләр: зур коңгызлар **«ж-ж-ж»** дип, кечкенәләр **«жь-жь-жь»** дип жуылдыйлар.

**2.** Тәрбияче **[ж]**, **[жь]** авазларының татар телендәге сүзләрдә генә очравын әйтә. **[ж]**, **[жь]** авазлары җил ыжылдавына бик охшаган, ләкин алар йомшаграк әйтеләләр. Тәрбияче балаларның игътибарын **[ж]** авазының — «кырыс», **[жь]** авазының «ягымлы» әйтелүенә юнәлтә.

**3. «Кайтаваз» уены.**

Тәрбияче **[ж]** авазы кергән сүзләрне, әлеге авазны тавыш белән аерып (көчәйтеп) әйтеп, балага туп ыргыта. Бала, сүзне нәкъ шул рәвешле кабатлап, тупны кире кайтара. Кирәк очракта сүзне бала белән бергәләп әйтергә дә мөмкин.






















**4.** Балаларга рәсемнәр буенча «ягымлы» **[жь]** авазы кергән сүзләрне табарга кушыла. Тәрбияче һәр сүзне бала белән бергәләп кабатлый һәм, интонация белән **жь-жь-жь** авазын аерып алып, көчәйтеп әйтү теләге уята.

**Сүзләр белән эш:**

**[жь]:** *җиләк, кәҗә, җилкән, җимлек, җимешләр, җир;*

**[ж]:** *җанвар, таҗ, җомга.*



**1.** Балалар тәрбияче белән бергәләп бүлмә буйлап черкиләр булып очып йөриләр: зур черкиләр — **«з-з-з»** дип, кечкенәләр — **«зь-зь-зь»** дип безелдиләр.


**2.** Тәрбияче балаларның игътибарын **[з]** һәм **[зь]** авазларының охшаш булуына, шул ук вакытта бер-берсеннән аермалы булурак, **[з]** авазының «кырыс», **[зь]** авазының «ягымлы» әйтелүенә юнәлтә.

**3.** Балаларга рәсемнәрдән «кырыс» **[з]** авазы кергән сүзләр табарга кушыла. Тәрбияче һәр сүзне бала белән бергәләп кабатлый һәм **[з]** авазын аерып әйтү теләге уята.








**4.** Рәсемнәр буенча балалар «ягымлы» **[зь]** авазы кергән сүзләрне эзләп табалар. Сүзләрне алдагы биремдәге кебек әйтеп бирәләр.

**Сүзләр белән эш:**

**[з]:** *коңгыз, карбыз, ваза, каз;*

**[зь]:** *зебра, тәрәзә, көзге, кәрзин, күзлек.*

Матур җәй житкәч,
Көннәр җылыткач,
Кырга чыгарбыз,
Җиләк җыярбыз.



**1.** Тәрбияче авазларны аерып алмыйча гына шигырьне укый. Бу шигырьдә нинди бөҗәкләр тавышын ишетүләрен сорый. Балаларның җавапларын тыңлагач, **[з]**, **[ж]** авазларын аерып алып, шигырьне тагын бер тапкыр укый.

**2.** Тәрбияче, **[ж]** авазын аерып алып, шигырьне кабатлап укыганнан соң, **[ж]** авазы кергән сүзләрне әйтергә куша (коңгызлар очуы ишетелгән сүзләр). **«ж-ж-ж»** авазын аерып алып, сүзләрне кабатлап чыга. Нәтиҗә ясый: «Без бу сүзләрдә **[ж]** авазын ишетәбез.»

**3.** Тәрбияче, **«з-з-з»** авазын аерып алып, шигырьне тагын бер кат укый һәм **[з]** авазы кергән сүзләрне әйтеп бирергә куша (зур черкиләр очуы ишетелгән сүзләр).





**4. Мөстәкыйль эш.**

Балалар зур һәм кечкенә черкиләр, зур һәм кечкенә коңгызлар өчен шарлар эзләп табалар. Шарларга җепләр ясап, шушы персонажлар белән тоташтыралар. Моның өчен шарлардагы рәсемнәрне атап чыгарга кирәк. Әгәр сүздә **[з]** авазы ишетелсә, бу шар зур черкинеке була, **[зь]** авазы ишетелсә — кечкенә черкинеке, **[ж]** авазы ишетелсә — зур коңгызныкы, **[жь]** авазы ишетелсә, кечкенә коңгызныкы була.

**Сүзләр белән эш:**

**[з]:** *казан, роза, бозау;*
**[зь]:** *зебра, күзлек;*
**[жь]:** *җиләк, җимлек;*
**[ж]:** *таҗ, боҗра.*



**1.** Тәрбияче балаларга каз һәм каз бәбкәсе белән бергәләп насослар белән эшләргә тәкъдим итә. «Каз зур насос белән эшләгәндә, **«с-с-с»** **[с]** авазын ишетәбез», – дип әйтә. Тәрбияче бу авазның «кырыс» яки «ягымлы» булуын билгеләргә куша. Каз бәбкәсе белән бергәләп кечкенә насос белән эшлиләр: **«сь-сь-сь»** һәм **[сь]** авазын әйтәләр, аның «ягымлы» икәнен билгелиләр.


**2.** Балалар рәсем буенча *песи* һәм *сарык* сүзләрен әйтәләр, сүзләрдәге «кырыс» **[с]**, «ягымлы» **[сь]** авазларының урынын билгелиләр.

**3.** Тәрбияче балаларның игътибарын рәсемдәге яшел һәм зәңгәр киемле малайларга юнәлтә.

Бу туганнар бер-берсенә бик охшаш, әмма аларның берсе — кырыс, икенчесе ягымлы. Икесенең дә яраткан авазлары бар. Балалар белән бергәләп *песи* һәм *сарык* сүзләренә туры килгән рәсемнәрне карыйлар. Кайсысы кырыс малайга, кайсысы ягымлыга туры килгәнне билгелиләр.























**4.** Тәрбияче балаларга рәсемдәге калган предметларны әйтеп чыгарга куша. Балалар «кырыс» **[с]** авазы кергән «сүзләр»не кырыс малай портреты белән, ә «ягымлы» **[сь]** авазы кергән «сүзләр»не ягымлы малай портреты белән тоташтыралар.


**Сүзләр белән эш:**

**[с]:** *сарык, сабын, сыер, сарымсак;*


**[сь]:** *песи, сөлге, кәбестә, сәгать.*













**1.** Тәрбияче рәсемнәрне атап чыгарга куша, балалар рәсемнәргә туры килгән сүзләрне әйтеп бирәләр.

**2.** Тәрбияче бу сүзләрне икенче төрлерәк итеп, бер авазны озаграк сузып әйтәчәге турында искәртә.

Башта тәрбияче **[л]** авазы кергән сүзләрне әйтә (*акул-л-ла, ал-л-л-ма, шал-л-л-кан*). Балалар аның артыннан кабатлыйлар: **«л-л-л»**, бу авазның дөрес әйтелеше өстендә эшлиләр.


Аннан соң **[ль]** авазы белән дә шундый ук эш башкарыла (*дел-л-ль-фин, фил-л-л, төл-л-лке*).

**3.** Тәрбияче **[л]** һәм **[ль]** авазларының «туганнар» булуын ассызыклап үтә. Алар бик тә охшаш, шул ук вакытта бер-берсеннән аерылалар да: **[л]** авазы — «кырыс», **[ль]** авазы «ягымлы» итеп әйтелә.























**4. Мөстәкыйль эш.**

Тәрбияче кырыс һәм ягымлы малайлар өчен рәсемнәр табарга тәкъдим итә.

Кырыс малайга «кырыс» **[л]** авазы кергән сүзләргә туры килгән рәсемнәр табыла һәм аның портреты белән тоташтырыла. Ягымлы малайга «ягымлы» **[ль]** авазы кергән сүзләргә туры килгән рәсемнәр табыла, аның портреты белән тоташтырыла.

**5. «Кайтаваз» уены.**

Тәрбияче сүзне әйткәндә, нинди дә булса авазны аерып алып, тупны балага ыргыта. Бала, сүзне нәкъ шулай ук кабатлап, тупны кире кайтара.

**Сүзләр белән эш:**

**[л]:** *алма, шалкан, акула, болан, крокодил, елан, балык;*

**[ль]:** *фил, төлке, дельфин, күбәләк, леопард, челән.*

## МЫРАУҖАН

Минем Мырауҗан исемле песием бар. Ул — ап-ак, йоп-йомшак песи. Аның мыеклары озын.

Мырауҗан каймак, сөт эчәргә ярата. Ул бик шаян. Әбиемнең йомгагын тәгәрәтеп уйный. Мырауҗан йокларга да ярата. Көннәр буе мыегын селкетеп йоклый, төнгә ауга чыга. Мин песиемне бик яратам.



**1.** Тәрбияче текстны ике тапкыр укып чыга. Балалар белән иллюстрация карыйлар.

**2.** Тәрбияче, **[м]**, **[мь]** авазларын интонация белән аерып алып, текстны тагын бер тапкыр укып чыга, нинди авазларның аеруча яхшы ишетелүен сорый.

**3. Мөстәкыйль эш.**

Балалар **[м]** авазы кергән сүзләргә туры килгән рәсемнәрне табалар, аларның һәркайсын кайсы малайныкы булуын ачыклыйлар. Аннан соң **[мь]** авазы кергән сүзләргә туры килгән рәсемнәрне табып, аларның кайсы малай өчен булуын билгелиләр.



9 нчы шөгыль

























**4. «Кем күбрәк сүз әйтә?» уены.**

Балалар арасында башта «кырыс» **[м]** авазы кергән сүзләр уйлап әйтү буенча, аннан соң «ягымлы» **[мь]** авазы кергән сүзләр уйлап әйтү буенча ярыш уздырыла. Дөрес әйтелгән сүз өчен фишка бирелә. Күбрәк фишка җыйган бала җиңүче итеп таныла.

**Сүзләр белән эш:**

**[м]:** *сарымсак, муенса, маймыл, йомгак, алма;*

**[мь]:** *мәк, миләш, мәче, гөмбә.*




**1.** Тәрбияче шигъри юлларны ике тапкыр укып чыга, балалар белән иллюстрация карыйлар.

**2.** Тәрбияче, **[н]**, **[нь]** авазларын интонация белән аерып алып, шигъри юлларны тагын бер тапкыр укып чыга. Кайсы авазларның аеруча яхшы ишетелүен сорый.

**3. Мөстәкыйль эш.**

Балалар **[н]** авазы кергән сүзләргә туры килгән рәсемнәрне табалар, аларның кайсы малай өчен булуын ачыклыйлар. Аннан соң **[нь]** авазы кергән сүзләргә туры килгән рәсемнәрне табып, аларның кайсы малай өчен икәнен билгелиләр.


**4. «Кайтаваз» уены.**

**[н]** һәм **[нь]** авазлары рус телендә дә, татар телендә дә очрый. Бу авазларга бик охшаган тагын бер аваз бар — **[ң]**. Бу аваз татар телендәге сүзләрдә генә очрый.












Тәрбияче, **[ң]** авазы кергән сүзләр әйтеп, тупны балага бирә. Бала, сүзне тәрбияче артыннан кабатлап, тупны кире кайтара (*кыңгырау, яңгыр, уңыш, таң, моң, дуңгыз, бәрәңге, чаңгы*).

**5. «Кем күбрәк сүз әйтә?» уены.**

Балалар арасында «кырыс» **[н]** авазы һәм «ягымлы» **[нь]** авазы кергән сүзләргә ярыш уздырыла. Аннан соң **[ң]** авазы кергән сүзләр әйтү буенча ярышалар. Һәр дөрес әйтелгән сүз өчен фишка бирелә. Күбрәк фишка җыйган бала җиңүче итеп танылa.

**Сүзләр белән эш:**

**[н]:** *чана, нарат, гармун;*
**[нь]:** *тиен, инә, имән;*
**[ң]:** *кыңгырау, яңгыр, уңыш, таң, моң, дуңгыз, бәрәңге, чаңгы.*





**1**. Балалар тәрбияче белән бергәләп **«Цирк аренасында юлбарыслар»** дигән рольле уен уйныйлар. Тәрбияче — дрессировщик ролендә. Ә балалар юлбарыслар булып «арена» буйлап йөриләр һәм «ырылдыйлар». Команда буенча тын гына «утыралар». Яңадан команда буенча «арена» буйлап йөриләр һәм «ырылдыйлар» **[р-р-р].**

**2.** Тәрбияче балаларның игътибарын **[р]** авазының «кырыс» һәм «ягымлы» булуына юнәлтә. Ата юлбарыс «кырыс» итеп ырылдый: **«р-р-р»**. Ана юлбарыс «ягымлы» итеп ырылдый: **«рь-рь-рь»**. «Юлбарысларның» ничек ырылдавы буенча тәрбияче кемнең ана юлбарыс, кемнең ата юлбарыс булуын билгели.

**3.** Тәрбияче исемнәрендә **[р]** авазы булган балаларга басарга куша. Балалар үзләренең исемендәге **[р]** авазының «ягымлы» яки «кырыс» булуын билгелиләр. Калган балаларның ни өчен бу төркемгә кермәүләре дә ачыклана.




















**4. Мөстәкыйль эш.**

«Кырыс» **[р]** авазы кергән сүзләргә туры килгән рәсемнәрне кырыс малай портреты белән, «ягымлы» **[рь]** авазы кергән сүзләргә туры килгән рәсемнәрне ягымлы малай портреты белән тоташтыралар.

**5. «Нәрсә белән охшаш, нәрсә белән аерыла?» уены.**

Балаларга хайван рәсемнәре күрсәтелә. «Алар арасында нинди охшашлык, нинди аерма бар? Аларның әйтелешендә нинди охшашлык, нинди аерма бар?» дигән сораулар бирелә.

*Сарык — сыер — арыслан*

*Бүре — кенгерә — керпе*

**Сүзләр белән эш:**

**[р]:** *сарык, сыер, арыслан;*

**[рь]:** *бүре, кенгерә, керпе.*

### «К»лар тулган бакчага

Бу бакчага ни булган?
Бакча «**к**» белән тулган:
**К**арлыган һәм **к**әбестә,
**К**ишер, **к**арбыз һәм **к**аба**к**,
**К**рыжовни**к**, **к**у**к**уруз,
**К**ыяр, **к**авын, **к**узгала**к**...
Әйдә, рәхим итегез!
Авыз итеп китегез!

*Роберт Миңнуллин*



**1.** Тәрбияче шигырьне ике тапкыр укып чыга. Балалар белән бергәләп иллюстрация карыйлар.

**2.** Тәрбияче, **[къ]** авазын интонация белән аерып алып, шигырьне тагын бер тапкыр укып чыга һәм бу авазның бары тик татар телендә генә кулланылуына балаларның игътибарын юнәлтә. Бу аваз һәрвакыт «калын» итеп әйтелә: **«къ-къ-къ»**. Татарча сөйләмдә рус теленнән кергән сүзләр дә еш очрый: *крыжовник, кукуруз*. Бу сүзләрдә дә **[к]** авазы «калын» булып яңгырый, ләкин ул икенче төрлерәк әйтелә: **«к-к-к»**.

**3.** Тәрбияче шигырьдәге «ягымлы» **[кь]** авазы кергән сүзләр турында сорый. Бу нинди сүзләр? (*Кишер, кәбестә.*)

**4. Мөстәкыйль эш.**


Балалар барлык рәсемнәрне дә атап чыгаралар. «Кырыс» **[къ]** кергән сүзләргә туры килгән рәсемнәрне кырыс малай портреты белән, «ягымлы» **[кь]** авазы кергән сүзләргә туры килгән рәсемнәрне ягымлы малай портреты белән тоташтыралар.



























**5. «Кайтаваз» уены.**

Тәрбияче, **[кь]**, **[к]**, **[къ]** авазлары кергән сүзләр әйтеп, балага туп ыргыта. Бала, тиешле авазны аерып алып әйтеп, сүзне кабатлый һәм тупны кире кайтара. Бу авазларны сузып әйтеп булмый. Алар көчлерәк яңгырашлы булулары белән аерылып торалар. Бу биремне үтәү бала өчен кыен булырга мөмкин. Шуңа күрә кирәк очракта сүзне бала белән бергәләп әйтергә дә була.

**Сүзләр белән эш:**

**[къ]:** *курчак, бака, тавык, акча;*
**[кь]:** *көзге, кишер, тәлинкә, күбәләк, күлмәк.*



Ике песи суга бара,
Көянтә-чиләк асып.
Ике тычкан карап кала,
Капка төбендә басып.

*(Халык авыз иҗаты)*

**1.** Тәрбияче такмакны укып чыга. Балалар белән бергәләп иллюстрация карыйлар, песи белән тычканны чагыштыралар, яттан өйрәнәләр.

**2.** Тәрбияче, **[п]**, **[пь]** авазларын интонация белән аерып алып, такмакны тагын бер тапкыр укып чыга. Балалар белән бергәләп башта «ягымлы» **[пь]** авазы кергән сүзләрне, аннан соң «кырыс» **[п]** авазы кергән сүзләрне табып әйтәләр.

**3. Мөстәкыйль эш.**

Балалар барлык рәсемнәрне дә атап чыгалар. «Кырыс» **[п]** авазы кергән сүзләргә туры килгән рәсемнәрне кырыс малай портреты белән, «ягымлы» **[пь]** авазы кергән сүзләргә туры килгән рәсемнәрне ягымлы малай портреты белән тоташтыралар.





**4. «Кайтаваз» уены.**

Тәрбияче, **[п]** һәм **[пь]** авазлары кергән сүзләр әйтеп, балага туп ыргыта. Бала, тиешле авазны аерып әйтеп, сүзне кабатлый һәм тупны кире кайтара. Кирәк очракта сүзне бала белән бергәләп кабатларга да мөмкин.

**Сүзләр белән эш:**

**[п]:** *помидор, чыпчык, китап, туп;*

**[пь]:** *пәрәмәч, пәлтә, ипи, җеп, песнәк.*



Вафли, слива һәм варенье —
Тәмле ризыклар алар.
Вафли, слива, вареньены
Яраталар балалар.

**1.** Тәрбияче шигъри юлларны укый, эшне алдагы дәресләрдәге кебек оештыра. Бу юлларда «кырыс» **[в]** авазының гына ишетелүе ачыклана. Балаларга бу авазның «ягымлы» туганын әйтеп бирергә тәкъдим итеЛӘ **[вь]**.

**2. Дидактик материал белән эш.**

Балалар тактадагы барлык рәсемнәрне бер-бер артлы атап чыгалар. «Кырыс» **[в]** авазы кергән сүзләргә туры килгән рәсемнәрне – кырыс малайга, «ягымлы» **[вь]** авазы кергән сүзләргә туры килгән рәсемнәрне ягымлы малайга «бүләк итәләр».

**3. «Кайтаваз» уены.**

**[в]** һәм **[вь]** авазлары рус телендә дә, татар телендә дә очрый.

Бу авазларга охшаган **[w]** авазы татар телендә генә кулланыла.

Тәрбияче, **[w]** яки **[wь]** авазлары кергән сүзләр әйтеп, балага туп ыргыта. Бала, сүзне нәкъ шулай ук кабатлап, тупны кире кайтара: *вакыт, табык, авыл, кавын, самавыр, Вәли, Вәсилә, Вәсимә, хәлвә.*






**4. «Дусларга үз рәсемнәрен табарга булыш!» уен-күнегүе.**


Балалар барлык рәсемнәрне дә атап чыгалар.

**[в]** һәм **[вь]** авазлары кергән сүзләргә туры килгән рәсемнәрне Вася исемле малай белән, **[w]** һәм **[wь]** авазы кергән сүзләргә туры килгән рәсемнәрне Вәли исемле малай белән тоташтыралар.

**Сүзләр белән эш:**

**[в]:** *ваза, слива;*
**[вь]:** *виноград, велосипед;*
**[w]:** *тавык, кавын, самавыр, савыт;*
**[wь]:** *хәлвә.*

 !
 !
 !
 !
 !

 !
 !
 !
 !
 !

**1.** Балалар өстәге рәттәге рәсемнәрне атыйлар, һәр сүзнең беренче авазын интонация белән әйтеп бирәләр. Аннан соң икенче рәттәге һәр сүзнең беренче авазын аерып әйтәләр. «Ягымлы» («кырыс») аваздан башланган «сүзләр» астындагы схемаларда беренче авазны яшел (зәңгәр) карандаш белән буяп куялар.

**2.** Балалар тәртип буенча өстәге рәттәге рәсемнәрне атыйлар, һәр сүзгә астагы рәттән дә шул ук аваздан башланган сүзне сайлап алалар.

**3.** Балалар рәсемнәрне атыйлар. Тәрбияче үрнәгендә, **[г]** һәм **[гь]** авазлары яхшы ишетелерлек итеп, сүзләрне тагын бер тапкыр кабатлыйлар — *гном, гитара.*

**4. Мөстәкыйль эш.** Балалар **[г]** авазы кергән сүзләргә туры килгән рәсемнәрне — кырыс малай портреты белән, **[гь]** авазы кергән сүзләргә туры килгән рәсемнәрне ягымлы малай портреты белән тоташтыралар.




15 нче шөгыль













**5. «Кайтаваз» уены.**

**[г]** һәм **[гь]** авазларына охшаган тагын бер аваз бар, ул — **[гъ]**. Бу аваз татар телендә генә очрый, кулланыла.

Тәрбияче, **[гъ]** авазы кергән сүзне әйтеп, тупны балага бирә. Бала, сүзне нәкъ шулай ук кабатлап, тупны кире кайтара (*карга, багана, таган*).

**Сүзләр белән эш:**

**[ль]:** *лимон, ләвәш;*
**[р]:** *роза, ромашка;*
**[кь]:** *кит, кишер;*
**[м]:** *маймыл, машина;*
**[пь]:** *пәлтә, пәрәмәч;*
**[г]:** *гном, гармун;*
**[гь]:** *гитара, күгәрчен, гөмбә, кәнгерә, сәгать;*
**[гъ]:** *карга, багана, таган.*

### Хат

Абый ерак җирләрдән
Солдат хаты җибәргән.
Җайлап кына утырдым —
Кычкырып хат укыдым.
Елап утырды әнкәм,
Тыңлап утырды әткәм,
Бик әйбәт хат — абыем
Миңа сәлам җибәргән!

*Роберт Миңнуллин*



**1.** Тәрбияче шигырьне укып чыга. Балалар белән иллюстрация карыйлар.

**2.** Тәрбияче, **[х]** авазын интонация белән аерып алып, шигырьне тагын бер тапкыр укып чыга. **[х]** авазы ишетелгән сүзне аерып алырга тәкъдим итә, *хат* сүзендә «кырыс» **[х]** авазының гына ишетелүе ачыклана. Бу авазның «ягымлы» туганын әйтеп бирергә куша **[хь]**.

**3. Мөстәкыйль эш.**

Балалар барлык рәсемнәрне дә атап чыгалар (*хат, халат, шахмат, хөрмә, хәреф*). «Кырыс» **[х]** авазы кергән сүзләрне кырыс малай рәсеме белән, «ягымлы» **[хь]** авазы кергән сүзләрне ягымлы малай рәсеме белән тоташтыралар.












**4. «Кайтаваз» уены.**


**[х]** һәм **[хь]** авазлары рус теленнән кергән сүзләрдә дә, татар телендәге сүзләрдә дә очрый. Ә менә бу авазларга бик охшаш, аларга караганда йомшаграк әйтелә торган **[һ]** авазы татар телендә генә кулланыла.

Тәрбияче, **[һ]** авазы кергән сүзләр әйтеп, тупны балага бирә. Бала, нәкъ шулай ук кабатлап, тупны кире кайтара (*һөнәр, һәйкәл, һава, шәһәр, Илһам ...*).

**5. «[һ] авазы кергән сүзләр уйлап әйт» уен-ярышы.**

**Сүзләр белән эш:**

**[х]:** *хат, шахмат, халат;*
**[хь]:** *хәреф, хөрмә, хәлвә;*
**[һ]:** *һөнәр, һәйкәл, шәһәр, һава, Илһам.*


! 


! 


! 


! 



! 


! 


! 


! 


! 


! 


! 


! 

**1.** Балалар рәсемнәргә туры килгән сүзләрнең беренче авазларын атыйлар.


**2.** Тәрбияче балаларның игътибарын һәр сүзнең пары булуына юнәлтә: бер сүз «ягымлы» аваздан башлана, ә икенчесе — «кырыс» аваздан. Балалар схемаларда беренче авазга туры килгән шакмакны зәңгәр яки яшел төскә буйыйлар.


**3. «Туганын тап» уены.**

Тәрбияче, калын тартык аваздан башланган сүз әйтеп, балага туп ыргыта. Бала, бу авазның нечкә парыннан башланган сүз уйлап әйтеп, тупны кире кайтара. Биремне алыштырырга да мөмкин: тәрбияче нечкә тартык аваздан башланган сүз әйтә, бала калын тартык аваздан башланган сүз белән җавап бирә.






! 


! 


! 


! 


! 


! 



! 


! 


! 


! 


! 


! 

**4. «Дөрес әйт» уены.** Тәрбияче артыннан балалар дөрес итеп сүзтезмәләрне кабатлыйлар (*Казан шәһәре, Тукай һәйкәле, карга боткасы, тавык ярмасы* ...).

**5. «Табышмак төзе һәм җавабының рәсемен яса. Җаваптагы сүзнең беренче һәм соңгы авазын әйт» биреме.**

**Сүзләр белән эш:**

**[б-бь]** *бака — бәрән,* **[л-ль]** *лампа — лимон,* **[х-хь]** *хат — хөрмә,* **[п-пь]** *пычкы — пәлтә,* **[р-рь]** *рам — рәшәткә,* **[ж-жь]** *җанвар — җиләк,* **[ф-фь]** *флаг — фил,* **[с-сь]** *сабын — себерке,* **[м-мь]** *машина — мәче,* **[къ- кь]** *карбыз — күгәрчен,* **[г-гь]** *груша — герб,* **[в-вь]** *ваза — виноград.*



1. Тәрбияче энесе белән урманга китеп адашкан кыз турындагы хикәядән өзек сөйли. Рәсем буенча хикәянең башын уйлап табарга куша.

2. «Балалар, урманда адашкач, «ау» дип кычкырырга кирәк».

Тәрбияче бу сүзнең беренче авазын сузып, кычкырып әйтергә куша. Балалар белән бергәләп үзе дә кычкыра: «А-а-а-ау!». Аннан соң сүзнең икенче авазын сузып әйтүләре сорала: «Ау-у-у!».

3. Тәрбияче *ау* сүзенең беренче авазын әйтергә куша. Тактада квадрат ясый: бу беренче **[а]** авазының «өе», ди. Аннан соң **[у]** авазы белән дә шундый ук эш алып барыла.

Күрсәткеч таяк белән беренче шакмакны күрсәтеп: «Беренче өйдә нинди аваз яши?» – дип сорый. Аннан соң икенче өйдә нинди аваз яшәгәнлеге сорала. Күрсәткеч таякны шакмаклар буйлап йөртеп, *ау* сүзен «укырга» тәкъдим ителә. Күрсәткеч таякны әле беренче шакмакта, әле икенче шакмакта озаграк тота. Шул рәвешле балада уку теләге уята.



















**4. Мөстәкыйль эш.**

Балалар рәсемнәрне атап чыгалар, **[а]** авазыннан башланган сүзләрне схемадагы **[а]** авазына туры килгән шакмак белән, **[у]** авазыннан башланган сүзләрне **[у]** авазына туры килгән шакмак белән тоташтыралар.

**5. «Кем күбрәк сүз әйтә?» уены.**


Балалар **[у]** авазы кергән сүзләр уйлап әйтәләр, һәр дөрес сүз өчен фишка бирелә.

**Сүзләр белән эш:**

**[а]:** *аю, агач, ат, автобус;*

**[у]:** *учак, уенчык, урындык, укучы.*






1. *Ат* сүзенә аваз анализы ясау:

а) схема буенча күрсәткеч таяк йөрешенә туры китереп, сүзне әйтеп бирү;

б) башта бер авазны, аннан соң икенче авазны интонация белән аерып алып әйтү (**а-а-ат** — беренче авазны билгеләү, **ат** — икенче авазны билгеләү);

в) билгеле бер авазны аерып алып әйтү һәм аның сүздәге урынын билгеләү;

г) авазны атаганнан соң, һәр авазны сары төстәге фишка белән билгеләү һәм схемада шул авазга туры килгән шакмакка кую;


д) схемадагы шакмаклар фишкалар белән капланып беткәннән соң, сүзне фишкалар — авазлар буенча, күрсәткеч таяк йөрешенә туры китереп «уку».

Тәрбияче сүз схемасына күрсәтеп нәтиҗә ясый: «Сүз схемасы буенча сүздә ничә аваз булуын белеп була. Фишкалы схема сүзнең моделе була».

Бу кагыйдәне балалар белән өйрәнергә кирәк түгел. Балалар тәрбиядченең нәрсәне «схема» дип, нәрсәне «модель» дип атавын аңласалар, шул җитә.








2. **«Тере модельләр» уены** (*ат* сүзе белән):

1) фишкалар авазларның тәртип номерлары буенча балаларга өләшенә;

2) балаларны чакырганда, авазларның тәртибе буташтырыла;

3) балалар схемага фишкаларны тәртип буенча куялар.

3. *Ут* сүзенә аваз анализы ясау.

4. *Ат* һәм *ут* сүзләрен чагыштыру:

а) Бу сүзләрдә нинди авазлар бертөрле?

б) *Ат* сүзендәге кайсы аваз *ут* сүзендә юк?

в) *Ут* сүзендәге кайсы аваз *ат* сүзендә юк?

Балалар бу сорауларга, кирәкле авазны аерып алып, схема буенча «укып» җавап бирәләр.

5. **«Кем күбрәк сүз әйтә?» уены**.

Балалар *ат* сүзендә дә, *ут* сүзендә дә булган авазлар кергән сүзләр уйлап әйтү буенча ярышалар.



**1.** Тәрбияче тубын ялгыш суга төшереп җибәргән Әминә турында шигырь сөйли. Рәсем буенча бу хәлнең ахырын уйлап табарга куша.


**2.** *Туп* сүзенә аваз анализы ясау. Алдагы дәрестә үзләштерелгән аваз анализына тагын бер бирем өстәлә: тартык авазны аерып алганнан соң, аның «кырыс» яки «ягымлы» булуы билгеләнә һәм туганын әйтергә кушыла. (*Туп* сүзенең беренче авазы **[т]** — бу «кырыс» аваз, аның «ягымлы» туганы — **[ть].**)

**3. «Тере модельләр» уены** (*туп* сүзе белән):


1) фишкалар авазларның тәртибе буенча өләшенә;
2) балаларны чакырганда, авазларның тәртибе буташтырыла;
3) балалар схемага фишкаларны авазларның тәртибе буенча куялар.













**4.** Схема буенча «укып», *туп* һәм *тун* сүзләрен чагыштыру. Башта бертөрле, аннан соң төрле-төрле авазларны табу. «*Туп* сүзендә **[п]** авазы урынына **[н]** авазын куйсак, нинди сүз барлыкка килер иде?» дигән сорау куела. Бу сүзләрне схема буенча тагын бер тапкыр «укырга» кирәк: *туп* — *тун*.


**5. «Кем күбрәк сүз әйтә?» уены.**

Балалар *туп* сүзенең соңгы авазы кергән сүзләр уйлап әйтү буенча ярышалар. «Кем күбрәк **[п]** авазының «ягымлы» туганы кергән сүзләр уйлап әйтә?» дигән сорау куеп, уенны дәвам итәргә мөмкин (**[пь]** авазын балалар үзләре әйтергә тиешләр). Дөрес җавап өчен бүләк — фишка.

## 21 нче шөгыль







**1.** *Мәк* сүзенә аваз анализы ясау.

**2. «Тере модельләр» уены** (*мәк* сүзе белән):

1) авазларны алмаштыручы фишкалар буташтырып бирелә;
2) авазларның тәртипләре буташтырылып, балалар чакырыла;
3) балалар авазлар схемасына фишкаларны тәртип буенча урнаштыралар.

**3. «Кем күбрәк сүз әйтә?» уены.**

Уен алдыннан балаларга рәсемнәргә игътибар итәргә кушыла. Рәсемнәр буенча балалар үзлекләреннән уенның шартына төшенергә тиешләр. Балалар *мәк* сүзенең беренче авазыннан башланган сүзләр уйлап әйтәләр (*мәк — миләш — мөгез* ...). Аннан соң бу авазның «кырыс» туганын атап (**[м]**), шушы аваздан башланган сүзләр уйлап әйтәләр (*малай — мылтык — морж* ...). Дөрес җаваплар өчен фишкалар бирелә.



## 22 нче шөгыль



**1.** «Сез беләсезме: *мук* ул...» дип кыскача мәгълүмат бирү.

**2.** *Мук* сүзенә аваз анализы ясау:

а) күрсәткеч таяк артыннан схема буенча сүз «уку»;
б) сүзне схема буенча күрсәткеч таяк артыннан беренче авазын аерып алып «уку»;
в) беренче авазны аерып әйтү һәм аны фишка белән билгеләү;
г) беренче авазның калынлыгын-нечкәлеген билгеләү һәм аның парын әйтеп бирү;
д) схема буенча икенче авазны аерып алып, күрсәткеч таяк ярдәмендә сүзне «уку»;
е) икенче авазны аерып әйтү һәм аны фишка белән билгеләү;
ж) схема буенча өченче авазны аерып алып, күрсәткеч таяк ярдәмендә сүзне «уку»;
з) өченче авазны аерып әйтү һәм аны фишка белән билгеләү;
и) өченче авазның калынлыгын-нечкәлеген («кырыс», «ягымлы») билгеләү һәм аның парын әйтеп бирү.



| | | |
|---|---|---|
| | | |



| | | |
|---|---|---|
| | | |

**3.** Тәрбияче балаларның игътибарын **[ү]** авазына юнәлтә, аны берничә тапкыр кычкырып кабатларга куша. Аннан соң балалар **[ү]** авазы кергән сүзләр уйлап әйтәләр (*үлән, үрдәк, үтүк, үлчәү, үкчә*).

**4.** *Мүк* һәм *мәк* сүзләрен чагыштыру:

а) Бу сүзләрдә нинди авазлар бертөрле?

б) *Мәк* сүзендәге кайсы аваз *мүк* сүзендә юк?

в) *Мүк* сүзендәге кайсы аваз *мәк* сүзендә юк?

**5. «Сүзне уйлап әйт» уены.**

Тәрбияче балага туп бирә. Бала, нинди дә булса «ягымлы» аваздан башланган сүз әйтеп, тупны кире кайтара.







| | | |
|---|---|---|
| | | |



| | | |
|---|---|---|
| | | |

**1.** *Күл* сүзенә аваз анализы ясау.

**2. «Тере модельләр» уены** (*мүк* сүзе белән):

1) авазларны алмаштыручы фишкалар буташтырылып бирелә;

2) авазларның тәртибе буташтырылып, балалар чакырыла;

3) балалар фишкаларны схемага тәртип буенча урнаштыралар.

**3.** *Күл* һәм *мүк* сүзләрен чагыштыру:


а) Бу сүзләрдә нинди авазлар бертөрле?


б) *Күл* сүзендәге нинди авазлар *мүк* сүзендә юк?

в) *Мүк* сүзендәге нинди авазлар *күл* сүзендә юк?

## 23 нче шөгыль




















**4. «Сүзләр чылбыры» уены.**


Тәрбияче, соңгы авазны интонация белән аерып алып, сүзне әйтә. Аның артыннан бала шушы аваздан башланган сүз уйлап әйтергә тиеш була. Тәрбияче бу сүзнең беренче һәм соңгы авазларын аерып әйтергә булыша. Шулай итеп, сүзләр чылбыры барлыкка килә.

**Сүзләр белән эш:** *кул — лимон — нота — ат ... (танк — карандаш — шахмат — такси — инә — әфлисун ...).*




## 24 нче шөгыль














**1.** *Кул* сүзенә аваз анализы ясау.

**2. «Тере модельләр» уены** (*кул* сүзе белән).

Балалар фишкаларны схемага куйган вакытта, тәрбияче нинди дә булса авазны махсус ялгыш әйтә: «**[кь]** авазы, схемада үз урынына бас!» Ул балаларның реакциясенә карый. Аннан соң биремдә «ялгыш» китүен, **[къ]** урынына аның ягымлы туганы **[кь]** аталуын әйтә. Болай әйткәндә, *кул* сүзе урынына *кул* сүзе килеп чыгуы ачыклана.


Такта янына чакырылган бала, башка балалар белән ярышып, схемадагы фишкаларны тәрбияче әйткәнчә җыеп ала.

**3.** *Сул* сүзенә аваз анализы ясау (*кул* сүзе схемасы астында).

Балаларга бу сүзнең мәгънәсе аңлатыла.

 →  → 

→ ?

 →  →  → ?

**4.** *Сул* һәм *кул*, *кул* һәм *кул*, *кул* һәм *мәк* сүзләрен чагыштыру.

*Кул* һәм *кул* сүзләрендәге **[къ]** һәм **[кь]** авазларына игътибар итәргә кушыла. Бу авазларны «бертөрле авазлар» дип уйлаучылар да булырга мөмкин (укый белүче балалар). Тәрбияче бу фаразның ялгыш булуын төшендерә.

**5. «Кем күбрәк сүз әйтә?» уены.**

Балалар арасында **[с]** авазыннан башланган «тәмле» сүзләр уйлап әйтү буенча ярыш уздырыла, һәр әйтелгән сүз өчен фишка бирелә.

**Сүзләр белән эш:** *сыр, слива ... (сөт, сок, сохари, салат, сумса ...).*








**1.** *Кул* сүзенә аваз анализы ясау.

**2. «Тере модельләр» уены** (*кул* сүзе белән).

**3.** *Кул* һәм *кул* сүзләрен чагыштыру.

Тәрбияче **[л]** һәм **[ль]** авазларына игътибар итәргә куша. Бу авазларның бертөрле авазлар булмавын искәртеп үтә: *кул* сүзендә **[ль]** — «ягымлы» аваз, *кул* сүзендә **[л]** — «кырыс» аваз.




**4.** Балалар барлык рәсемнәрне дә атап чыгалар. «Бу рәсемнәрнең әйтелешендә нинди охшашлык бар?» дигән сорауга җавап бирәләр. (Барлык сүзләр дә «ягымлы» аваздан башланалар.)

Балалар бу сүзләрнең беренче авазларын интонация белән аерып әйтеп бирәләр.

**5. «Дөрес әйт»** (туп белән уен).

Тәрбияче тупны балага бирә. Бала, нинди дә булса «ягымлы» аваздан башланган сүз әйтеп, тупны кире кайтара.

**Сүзләр белән эш:** *песнәк, җеп, төлке, диван, гитара, сәгать, бегемот, кишер, мәк, шикәр, зебра, чиләк.*










**1.** *Тоз* сүзенә аваз анализы ясау.
**2.** *Көз* сүзенә аваз анализы ясау.
**3.** *Тоз* һәм *көз* сүзләрен чагыштыру.

Тәрбияче **[з]** һәм **[зь]** авазларына игътибар итәргә куша. Бу авазларның төрле булуын исләренә төшерә. *Тоз* сүзендә **[з]** — «кырыс» аваз, *көз* сүзендә **[зь]** — «ягымлы» аваз.

## 26 нчы шөгыль



**4.** Балалар барлык рәсемнәрне дә атап чыгалар. «Бу рәсемнәрнең әйтелешендә нинди охшашлык бар?» дигән сорауга җавап бирәләр. (Барлык сүзләр дә «кырыс» аваздан башлана.) Балалар бу сүзләрнең беренче авазларын интонация белән аерып алалар.


**5. «Дөрес әйт»** (туп белән уен).

Тәрбияче тупны балага бирә. Бала, нинди дә булса «кырыс» аваздан башланган сүз әйтеп, тупны кире кайтара.

**Сүзләр белән эш:** *пычак, кояш, сабын, шарф, балык, тукран, дага, хат, гармун, нарат, маймыл, рам.*



## 27 нче шөгыль





**1.** Рәсем астында — сүзнең аваз төзелеше схемасы. Балалар барлык рәсемнәрне дә атап чыгалар.

**2.** Тәрбияче «тылсымлы» сузык авазлар турында хикәя сөйли (85 бит).

**3.** *Шар, мәк* сүзләренә аваз анализы ясау, сузык авазны табу. Сузык авазны билгеләү өчен кызыл төстәге фишка кертелә.

**4.** *Туп, күл* сүзләрендәге сузык авазларны балалар мөстәкыйль эзләп табалар. (җавапларның дөреслеге такта янында тикшерелә).

**5.** Хәзерлекләре яхшырак булган балалар такта янында *тоз, көз* сүзләренә аваз анализы ясыйлар һәм бу сүзләрдәге сузык авазларны билгелиләр.



### 6. «Бу нинди сүз?» уены.

Балалар тәрбияче белән бергәләп ребус чишәләр. Алар рәсемнәргә туры килгән сүзләрне атап чыгалар, бу сүзләрнең беренче авазларын аерып алып, алардан яңа сүз төзиләр.

Беренче ребусны балалар тәрбияче белән бергәләп чишәләр, калганнарын мөстәкыйль чишү мөмкинлеге бирелә.


**Сүзләр белән эш:**

**[ш]:** *шарф, шар;*
**[а]:** *алма;*
**[р]:** *рам;*
**[м]:** *миләш, мәк;*
**[ә]:** *әтәч;*
**[к]:** *кәбестә, күл, күлмәк, күз, күнгерә;*
**[ү]:** *үрдәк;*
**[л]:** *лимон;*
**[ө]:** *өстәл;*
**[з]:** *зебра;*
**[т]:** *түп, тоз.*









**1.** *Бала* сүзенә аваз анализы ясау. Тәрбияче бу схеманың дүрт шакмаклы булуына игътибар итәргә куша. Моның нәрсә аңлатканын сорый. Аваз анализы күнегелгән тәртиптә үткәрелә, ләкин сузык авазларны аерып алганнан соң, өстәмә сораулар куела:

а) Бу нинди аваз? (*«Тылсымлы» сузык аваз.*)

б) Сузык авазларны без ничек таныйбыз? (*Сузык авазларны әйткәндә, авызда һава каршылыкларга очрамый.*)

**2. «Тере модельләр» уены** (*бала* сүзе белән):

1) фишкалар авазларның сүздәге тәртип номерлары буенча өләшенә;

2) балаларны чакырганда, *сүздәге беренче сузык аваз, икенче сузык аваз, сүздәге беренче аваз, сүздәге өченче аваз* дип әйтергә кирәк. Аннан соң авазлар балалар белән күмәкләп әйтелә;

3) балалар, авазларның тәртип номерларын буташтырып, фишкаларны схемага куялар. Хәзерлекләре яхшырак булган балалар фишкаларны схемадан алырга чакырыла: *сүздәге беренче аваз, сүздәге беренче сузык аваз, сүздәге өченче аваз, сүздәге икенче сузык аваз.*

## 28 нче шөгыль









**3. Мөстәкыйль эш.**

Балалар әчтән генә рәсемне атыйлар һәм сүз схемасында сузык авазларны кызыл карандаш белән тамгалыйлар («+» белән билгелиләр).

*Үлән* сүзе тактада тикшерелә. Тәрбияче интонация белән беренче авазны аерып ала: *ү-ү-ү-лән* һәм «+» тамгасы куя. Аннан соң өченче авазны аерып ала: *үлә-ә-ән*, аның урынына да «+» тамгасы куя.

**Сүзләр белән эш:** *үлән, дару, роза, төн.*



## 29 нчы шөгыль







**1.** *Лалә* сүзенә аваз анализы ясау. Сүзне тикшергәннән соң, тәрбияче беренче һәм өченче авазларны атарга куша. Балалар **[л]** авазының «кырыс», **[ль]** авазының «ягымлы» булуын билгеләп үтәләр. Бу авазларның сузык авазмы, түгелме икәнен ачыклыйлар.

Сузык аваз булмаган авазлар «тартык авазлар» дип аталалар.


«Кырыс» аваз — калын әйтелә торган тартык, «ягымлы» аваз — нечкә әйтелә торган тартык була. Яңа фишкалар кертелә: зәңгәр фишка — калын әйтелешле тартык аваз, яшел фишка — нечкә әйтелешле тартык аваз. Модельдәге сары фишкалар яшел һәм зәңгәр фишкалар белән алмаштырыла. Тәрбияче такта янындагы бала белән бергәләп фишкаларны алмаштыра, аларның нәрсә аңлатканын тагын бер тапкыр аңлатып бирә.


**2.** *Лалә* сүзенең моделен анализлау — сүздә дүрт аваз бар: ике сузык аваз һәм ике тартык аваз. Берсе — калын әйтелә торган тартык **[л]**, икенчесе — нечкә әйтелә торган тартык **[ль]**.

**3.** *Зифа* сүзенең моделен анализлау — бу сүздә дүрт аваз бар: ике сузык аваз, ике тартык аваз: берсе нечкә әйтелә торган тартык **[зь]**, икенчесе калын әйтелә торган тартык **[ф]**.





















**4. «Тере модельләр» уены** (*Зифа* сүзе белән):

1) фишкалар авазлар тәртибе буенча өләшенә;

2) балалар сузык авазларны һәм тартык авазларны тәртип буенча әйтеп чакырылалар: *беренче сузык аваз, икенче сузык аваз, калын әйтелә торган тартык аваз, нечкә әйтелә торган тартык аваз;*

3) балалар схемага фишкаларны авазларның номерларын буташтырып куялар;


4) материалны яхшырак үзләштергән балалар фишкаларны схемадан алырга чакырылалар: *беренче тартык аваз, беренче сузык аваз, икенче тартык аваз, икенче сузык аваз.*


**5. Мөстәкыйль эш.**

Балалар рәсемнәргә туры килгән сүзләрнең беренче авазларын зәңгәр, яшел, кызыл карандашлар белән билгеләп чыгалар.

**Сүзләр белән эш:** *утюк, карбыз, кит, скрипка, көнбагыш, пычкы, мәче, әтәч, чия.*







**1. «Игътибарлы бул!» уены.**

Һәр бала алдында өчәр фишка — кызыл, яшел һәм зәңгәр. Тәрбияче теләсә кайсы авазны атый. Ә балалар шул авазга туры килгән фишканы күрсәтергә тиеш булалар.

**2.** *Бака* сүзенә аваз анализы ясау. Һәр авазны аерып әйткәннән соң, яңа биремнәр өстәлә:

а) Бу аваз сузыкмы, тартыкмы?

б) Моны исбатла (әгәр дә бала ялгышса, тәрбияче белән бергәләп, аны төзәтү өстендә эшли).

в) Сузык аваз нинди фишка белән билгеләнә?

г) Тартык аваз калын әйтеләме, әллә нечкәме?

Әгәр дә бала читенсенеп торса, бу аваз парлап әйтелә: **[б] — [бь]**.

д) Калын әйтелә торган тартык аваз нинди фишка белән билгеләнә?

е) Авазның парын әйтеп бир.

**3.** *Кәҗә* сүзенә аваз анализы ясау.

**4.** *Бака* һәм *кәҗә* сүзләренең модельләрен чагыштыру: һәр сүздә дүртәр аваз, икешәр сузык аваз, икешәр тартык аваз. Ике сүздә дә сузык авазлар икенче һәм дүртенче урында, ә тартык авазлар беренче һәм өченче урында торалар. *Бака* сүзендә ике тартык аваз да калын, *кәҗә* сүзендә ике тартык аваз да нечкә әйтелә.

**5. «Сүзне уйлап әйт» уены.**

Башта балаларга сузык аваздан башланган сүзләр уйлап әйтергә тәкъдим ителә. Аннан соң бирем үзгәртелә:

а) калын әйтелә торган тартык аваздан башланган сүзләр әйтегез;

б) нечкә әйтелә торган тартык аваздан башланган сүзләр уйлап әйтегез.

Һәр дөрес сүз өчен фишкалар бирелә.

31 нче шөгыль

63



**1. «Игътибарлы бул!» уены.**

Уен алдагы дәрестәге кебек, ләкин мөмкин кадәр кызурак темпта үткәрелә.

**2.** *Ләлә* сүзенә аваз анализы ясау.

**3. «Тере модельләр» уены** (*Ләлә* сүзе белән).

Башта сүзнең моделе турында фикер алышыгыз: ничә сузык аваз бар? Сузык авазлар сүздә ничәнче урында торалар? Ничә тартык аваз бар? Тартык авазлар сүздә ничәнче урында торалар?

1) Билгеле бер тәртиптә фишкалар өләшенә: *беренче тартык аваз, икенче тартык аваз, беренче сузык аваз, икенче сузык аваз.*

2) Балалар авазларның тәртип номерлары буенча урыннары буталштырып чакырыла: *беренче сузык аваз* **[ә]**, *беренче тартык аваз* **[л]**, *икенче сузык аваз* **[ә]**, *икенче тартык аваз* **[л]**.

3) Схемага фишкаларны куйганда да авазларның урыннары буталштырып әйтелә.

**4.** *Ләлә* сүзенең моделен *лалә* сүзе моделенә үзгәртү.

Башта фишкалар буенча *Ләлә* сүзен «укырга», аннан соң *лалә* сүзен «укырга» кирәк. «*Ләлә* сүзен *лалә* сүзенә үзгәртү өчен кайсы фишканы алмаштырырга кирәк?» — дип сорала.





















**5. Мөстәкыйль эш.**

Балалар рәсемнәргә туры килгән сүзләрнең беренче авазларын зәңгәр, яшел, кызыл төсләр белән билгеләп чыгалар.

**Сүзләр белән эш:** *мәрҗән, үтүк, кулчатыр, кәҗә, автобус, бәрәңге, туп, ат, бака.*





**1.** *Алка* сүзенә аваз анализы ясау. *Алка* сүзенең моделе турында сөйләгәндә шуңа игътибар итәргә кирәк: монда сүзнең башында да, ахырында да сузык авазлар, уртада ике тартык аваз.

**2. «Тере модельләр» уены** (*алка* сүзе белән):


1) фишкалар авазларның урнашу тәртибендә өләшенә;


2) балалар сузык, тартык авазлар тәртибе буенча чакырыла: *беренче сузык, икенче сузык һ.б.;*

3) балалар, авазларның тәртибен буташтырып, схемага фишкалар куялар.

**3.** *Алка* сүзенең моделен *Әлки* сүзенең моделенә үзгәртү (алдагы дәресне карарга).











**4. Мөстәкыйль эш.**

Балалар рәсемнәргә туры килгән сүзләрнең беренче авазларыннан *алка* һәм *Әлки* сүзләрен төзиләр.

**5. «Йорт төзибез» уены.**

Тактада зур гына квадрат ясалган. Балалар йортның өлешләрен атарга тиешләр, ә тәрбияче шул өлешләрдән йорт төзи. Ләкин уенның шарты шундый: балалар әйткән сүзләрдә **[а]**, **[ә]** авазлары булырга тиеш (*түбә, такта, стена, тәрәзә, морҗа, баскыч* ...). Бакча, ишегалды, йорт җиһазларын атап, уенны дәвам итәргә мөмкин.





**1. «Минем исемем ничек?» уены.**

Тәрбияче фишкаларны бүлмәнең төрле җиренә куя, мәсәлән: тәрәзә төбенә кызыл фишка, тактага — зәңгәр, ишеккә — яшел. Эш барышында бу фишкаларның нинди авазларны белдерүләре ачыклана. Балаларга үз исемнәрен әйтергә һәм аның беренче авазын билгеләргә тәкъдим ителә. Бу авазның нинди аваз булуы ачыклана (сузык, калын әйтелә торган тартык, нечкә әйтелә торган тартык).

Тәрбияче сигналы буенча, балалар үз фишкалары янына барып басалар. Бирем үтәлешенең дөреслеген балалар үзләре тикшерәләр. Тәрбияче күзәтеп кенә тора.


**2.** *Шарф* сүзенең моделен тикшерү.

**3. «Тере модельләр» уены** (*шарф* сүзе белән).

**4.** *Арба* сүзенә аваз анализы ясау. Модельне тикшерү.

**5.** Модельләре буенча *шарф* һәм *арба* сүзләрен чагыштыру: аларда бертөрле авазларны табып, кызыл төс белән билгеләү.





**6.** Рәсемнәргә туры килгән сүзләрне атау. Аларның модельләрен табу һәм тиешле рәсемнәр белән тоташтыру.

**Сүзләр белән эш:** *шар, китап, алма, ипи, роза, көз.*









1. *Корт* сүзенә аваз анализы ясау. Сүзнең моделен тикшерү.
2. **«Тере модельләр» уены** (*корт* сүзе белән).
3. *Торт* сүзенә аваз анализы ясау. Сүзнең моделен тикшерү.


*Корт* һәм *торт* сүзләрен чагыштыру, бертөрле авазларын табу. Рус теленнән кергән сүзләрдәге һәм татар теленең үз сүзләрендәге **[о]** авазының аермасына игътибар итү.



**4. Мөстәкыйль эш.**
Балалар рәсемнәрне аларның исемнәренә туры килгән модельләр белән тоташтыралар.


**5.** Күп мәгънәле *корт* сүзе өстендә эш (бал корты, агач корты, ашый торган корт — озак кайнатылган эремчек).

**Сүзләр белән эш:** *чана, кәҗә, чыршы, акча.*
























**1.** *Клоун* сүзенә аваз анализы ясау. Сүзнең моделен тикшерү.
**2.** *Гөмбә* сүзенә аваз анализы ясау.
**3. «Тере модельләр» уены** (*гөмбә* сүзе белән).


**4. «Модель буенча сүзне әйт» уены.**

Тактада өч фишка: зәңгәр, кызыл, зәңгәр. Бу модельгә туры килгән сүзләр табып әйтергә кирәк. Тәрбияче *кар* сүзен атый. Аны модель буенча «укый». Балалар бу сүзнең әлеге модельгә туры килүен ачыклыйлар. Аннан соң тәрбияче модель буенча *кара* сүзен «укып» карый. Соңгы авазның модельгә сыймавын аңлата.

Балалар атаган һәрбер сүзне тәрбияче күрсәткеч таяк ярдәмендә күрсәтеп «укый» (беренче модельгә туры килгән сүзләр: *кар, сыр, душ* ..., икенче модельгә туры килгән сүзләр: *мәк, күл, фил* ...).

**Сүзләр белән эш:** *кар, сыр, душ, мәк, күл, фил.*





**1.** *Тел* сүзенә аваз анализы ясау.

Беренче һәм өченче авазларны такта янында балалар үзләре әйтеп бирәләр. Икенче авазны тәрбияче әйтә: схема буенча икенче авазны аерып алып, күрсәткеч таяк ярдәмендә сузып «укый», балаларга да үзе артыннан кабатларга куша.

Монда шуны истә тотарга кирәк: хәрефләрне белгән балалар **[э]** авазы урынына *е* хәрефен атарга мөмкиннәр, дөреслəү өчен сүзне тагын бер тапкыр «укыйлар» һәм икенче шакмакта **[э]** авазы яшәвен ачыклыйлар. *Тел* сүзендә *е* хәрефе язылса да, хәзер хәрефне түгел, авазны ишетергә кирәклеге аңлатыла. Тәрбияче: «Соңрак без татар телендә кайсы авазлар нинди хәрефләр белән билгеләнүен белербез. Ә хәзергә без *тел* сүзендә нинди авазлар ишетелүен тыңларга һәм ишетергә тиешбез», — дип нәтиҗә ясый.

**2. «Тере модельләр» уены** (*тел* сүзе белән):

1) тәрбияче фишкаларны авазларның сүздәге тәртибе буенча өләшә (сүзнең икенче авазы **[е]** дип уйлаучы балага **[э]** авазы роле бирелә);
2) тәрбияче балаларны авазларның урыннарын буташтырып чакыра;
3) балалар аралаштырып бирелгән авазларның фишкаларын схемага куялар.















**3.** *Сер* сүзенә аваз анализы ясау.
**4.** *Тел* һәм *сер* сүзләрен чагыштыру.
**5. «Кем күбрәк сүз әйтә?» уены.**

Уенны башлар алдыннан, тәрбияче дәфтәрдәге рәсемнәргә игътибар итәргә куша: башта *тел* сүзенең беренче авазыннан **[ть]** башланган сүзләр уйлап әйтергә кирәк, аннан соң, **[ть]** авазының «кырыс» туганын атап **[т]**, шул аваздан башланган сүзләр уйлап әйтергә кирәк.

**Сүзләр белән эш:**

**[т]:** *тукран, тамчы, тычкан, трактор;*
**[ть]:** *тиен, тәлинкә.*



**Ыргак**

Бер караганда — ыргак,
Бер караганда — кармак.
Ыргакка капкан балык,
Карыйммы суга салып?

*Роберт Миңнуллин*

**1. [ы]** авазын интонация белән аерып алып, тәрбияче шигырьне укып чыга. Балалар белән иллюстрация карыйлар. Балаларда аңа кушылып сөйләү теләге уяту максатыннан, тәрбияче шигырьне кабатлап укый.

**2.** *Ыргак* сүзенә аваз анализы ясау. Сүзнең моделен тикшерү.


**3. «Тере модельләр» уены** (*ыргак* сүзе белән).













**4.** *Ыргак* һәм *сыр* сүзләрен чагыштыру (рус теленнән кергән сүзләрдә һәм татар телендәге сүзләрдә **[ы]** авазының әйтелешенә игътибар иту).


**5. «Бу әйбер кемнеке?» уены.** Тәрбияче рәсемнәр күрсәтә. «Бу әйбер кемнеке?» дигән сорау бирелә. Балалар җавап биргәндә, **-ке**, **-кы** кушымчаларын дөрес итеп ялгап әйтергә тиешләр (бу күзлек әбине**ке**, бу түбәтәй бабайны**кы** ...).

**6. Мөстәкыйль эш.**

Балалар эштән генә рәсемне атыйлар һәм сүз схемасында сузык **[ы]** авазын кызыл карандаш белән тамгалыйлар («+» белән билгелиләр).

**Сүзләр белән эш:** *ыргак, ылыс, сыр, чыбыркы, сыбызгы, чыршы.*





**1.** «Сез беләсезме: *ипи* ул...» дип кыскача мәгълүмат бирү.

**2.** *Ипи* сүзенә аваз анализы ясау. Тәрбияче **[и]** авазын аерып алырга булыша. *Ипи* сүзенең моделе турында сөйләгәндә, сүзнең уртасында тартык аваз, башында һәм ахырында сузык авазлар булуына игътибар итәргә куша.

**3. «Тере модельләр» уены** (*ипи* сүзе белән).

**4.** *Ипи* сүзендәге **[и]** авазларын **[а]** авазына алмаштыру, *апа* сүзенең моделен тикшерү.

*Ипи* һәм *апа* сүзләрен чагыштыру.






**5. «Дусларга үз рәсемнәрен табарга булыш!» уен-күнегүе.**

Балалар барлык рәсемнәрне дә атап чыгалар. **[ы]** авазы кергән сүзләргә туры килгән рәсемнәрне — Камыр батырга, **[и]** авазы кергән сүзләргә туры килгән рәсемнәрне Ибраһим исемле малайга «бүләк итәләр».

**Сүзләр белән эш:**

**[и]:** *ипи, имән, итек, иләк, чиләк, шикәр, песи, чеби, сохари, инә;*

**[ы]:** *кавын, карбыз, кысла, чыпчык, пычкы.*

## 39 нчы шөгыль





**1.** *Май* сүзенә аваз анализы ясау. Тәрбияче **[й]** авазын аерып алырга булыша, аның нечкә әйтелә торган тартык аваз булуын һәм калын парының булмавын аңлата.

**2.** *Майка* сүзенә аваз анализы ясау, *майка* сүзенең моделен тикшерү.

**3.** *Май* һәм *майка* сүзләрен чагыштыру.

**4. «Тере модельләр» уены** (*майка* сүзе белән).

**5. «Нишли? дигән сорауга сүзләр уйлап әйт» биреме.**

Тәрбияче **[й]** авазына тәмамланган фигыльләрдән мисал китерә (укый, саный, уйный, уйлый, җырлый...), балаларга да шундый ук сүзләр уйлап әйтергә куша.

**Сүзләр белән эш:** *май, майка.*



## 40 нчы шөгыль

Йорт төзеде абыйларым:
Очты гына йомычка!
Шуны җыеп өеп бардым —
Ярдым бит йомышка!

*Ренат Харис*






**1.** Тәрбияче шигырьне укый, хәрефләрне белгән балаларга беренче сүзне укырга тәкъдим итә. Бу сүзнең нинди хәрефтән башлануын сорый. *Май* сүзенең ахырында ишетелгән **[й]** авазын искә төшерәләр.

**2.** *Йорт* сүзенә аваз анализы ясау.

**3.** Тәрбияче *юкә* сүзенә аваз анализы ясый. Схема буенча күрсәткеч таяк ярдәмендә сүзне укыганда, аның укылышына аерата игътибар итәргә кирәк. Балалар **[йу]** — **[й]** һәм **[у]** авазларын ачык ишетергә тиешләр. Берничә бала нәкъ шулай ук итеп «укырга» такта янына чакырыла. Укый белгән балалар беренче аваз — **[ю]** дияргә мөмкин. Бу очракта *юкә* сүзенең беренче хәрефе **«ю»** икәнен, ләкин аның ике аваздан торуын аңлатырга кирәк: **[йу]**. Мондый сораулар булмаса, бу турыда әйтергә кирәкми.

**4. «Сүзләр уйлап әйт» уены.**

Балалар **[йу]** һәм **[й]** авазыннан башланган сүзләр уйлап әйтәләр *(юл, юрган, йокы, йод, йомран, йолдыз, йомырка).*









**1.** *Юрган* сүзенә аваз анализы ясау. Яхшырак белүче бала такта янына чакырыла. Аннан соң сүзне «укырга» тагын берничә баланы чакырырга мөмкин.

**2. «Тере модельләр» уены** (*юрган* сүзе белән):

1) сүзнең авазларын белдергән фишкалар өләшенә;
2) балалар сузык һәм тартык авазлар буенча чакырыла;
3) балалар сузык, калын әйтелә торган тартык, нечкә әйтелә торган тартык авазлар буенча фишкаларны схемага куялар.
















**3.** Балалар рәсемнәрне атыйлар. Схемаларда нечкә әйтелә торган тартык **[й]** авазын белдергән яшел фишкаларга игътибар итәргә кушыла.

**4. «Сүзләр уйлап әйт» уены.**

Башта балалар **[й]** авазы уртада булган сүзләр уйлап әйтәләр, аннан соң **[й]** авазыннан башланган сүзләр әйтәләр.

**Сүзләр белән эш:** *юрган, йод, йолдыз, курай, йөзек, чия, яшен, каймак, ябалак, йомгак.*








**1.** *Күз* сүзенә аваз анализы ясау. *Күз* сүзенең моделен тикшерү.

**2.** Тәрбияче *күз* сүзенең моделен *күзлек* сүзенең моделенә үзгәртергә тәкъдим итә. Моны ничек башкарырга? Балалар, тәрбияче күзәтүе астында, *күз* сүзенең моделен үзгәртмичә генә, аңа яшел **[ль]**, кызыл **[э]** һәм яшел **[кь]** фишкалар өстәп, *күзлек* сүзенең моделен төзиләр. Биремне тизрәк үтәгән бала такта янына чакырыла һәм сүзне модель буенча «укый», нәрсәләр эшләгәнен сөйләп бирә.



42 нче шөгыль



**3. «Тере модельләр» уены** (*күзлек* сүзе белән).

**4. «Модель буенча сүзне әйт» уены.**

Бу уен балаларга таныш булса да, аның кагыйдәсен кабатлап үтәргә кирәк. Уен *туп* сүзенең моделе мисалында аңлатыла. Аннан соң рәсемнәрдән калган модельләргә туры килгән сүзләр дә табыла. Балаларның үзләреннән дә һәр модель буенча сүзләр уйлап әйттереп, уенны дәвам итәргә мөмкин.

**Сүзләр белән эш:** *туп, тун, сабын, балык, мәк, фил, җимлек, алка, арба.*

## «Тере модельләр» уены

— Ә хәзер уйнап алабыз. Сез хәзер *мәк* сүзенең авазлары буласыз. Сүзнең беренче авазы нинди аваз? Схема буенча, күрсәткеч ярдәмендә укыйсыз: **м-м-мәк**.

Дөрес җавап биргән бала такта янына чыга, ул фишканы ала, «**[м]** авазы» була. Шул рәвешле, схема буенча сүзне укып, икенче һәм өченче «авазлар» билгеләнә һәм такта янына чакырыла.

— Әгәр дә монда фишкалар булмаса яки авазлар тәртип белән басмасалар, без сүзне укый алыр идекме? Ягез әле, «авазлар», тәртип буенча басыгыз. Балалар, «авазлар»га үз урыннарына басарга ярдәм итегез. Аннан соң, күрсәткеч белән фишкалар буенча йөртеп, сүзне күмәкләп укырбыз.

Бу уенны икенче вариантта да тәкъдим итәргә була.

— *Мәк* сүзенең «икенче авазы», минем янга кил әле. Ә хәзер «беренче авазы», аннан соң «өченче авазы» килер.

Авазлар үз урыннарына басалар дип фараз ителә. Балалар, тәрбияче белән бергәләп, фишкалар буенча «сүз»не укыйлар.

Әгәр дә, беренче шөгыльдә балалар сез чакырган тәртиптә тезелеп бассалар, һәр баладан «Син нинди аваз?», — дип сорарга кирәк.

«Әйтегез әле, *мәк* сүзе килеп чыктымы?» — дип сораганнан соң да, «аваз»лар ялгышларын аңламасалар, үз урыннарына басмасалар, авазларны алар баскан тәртиптә укып күрсәтегез: *әмк*.

Бу очракта балаларның ялгышларына аерым басым ясамаска кирәк, киресенчә, гаҗәпләнеп «Ни өчен *мәк* сүзе килеп чыкмады соң? Әллә авазлар урыннарын бутадылармы икән?» дигән сораулар куела. Моннан соң «авазлар», үз ялгышларын аңлап, дөрес итеп басарга тиешләр.

Бу биремнәрнең балалар өчен авыр булуын истән чыгармаска кирәк. Югарыда күрсәтелгән биремнәрне беренче чиратта «авазлар» вазифасын үти алырлык балаларга тәкъдим итәргә кирәк. Әгәр дә балалар «йомшаграк» булсалар, аларга һәр адымны әйтеп торырга кирәк: «Минем янга **[ә]** авазы килә», — һәм, **[ә]**нең килүен дә көтмичә: «Әйе, Алсу, син **[ә]** авазы, уртага бас». Шулай итеп беренче һәм өченче «аваз»ларны да чакырырга мөмкин. Калган балалар, сезнең әйтеп торганыгызны сизмичә дә калып, «авазлар» бик яхшы итеп биремне «үтәделәр» дип уйлаячаклар. Шул рәвешле аларда үз-үзләренә ышаныч һәм актив булу теләге уяначак.

Балаларны урыннарына утыртканчы, фишкаларны сүз схемасына куярга кушыгыз һәм, схема буенча сүзне «укып», авазларның урыннарын истә калдыртырга тырышыгыз. Ә фишкаларны схемадан алган вакытта үзегез белән балалар арасында уен-ярыш үткәреп алыгыз.



## «Тылсымлы» авазлар турында

Әлифба битләрендә кайбер сүзләрнең аваз төзелеше схемасы бирелгән: *шар, туп, мәк, күл, тоз, күз.*

Бу сүзләрнең һәрберсендә дә берәр «тылсымлы» аваз бар. Бу авазлар шундый рәхәт итеп, иркен итеп әйтеләләр.

Ул авазларны әйткәндә, иреннәр дә, тешләр дә, тел дә комачауламый. «Тылсымлы авазлар»ны озак итеп сузарга, җырларга, яисә кычкырырга да мөмкин.

Тәрбияче балаларга *шар* сүзендәге «тылсымлы» авазны бергәләп эзләп табарга тәкъдим итә. Тәрбияче такта янына бер баланы чакыра. Ул бала, күрсәткечне әкрен генә схема буенча йөртеп, сүзне кычкырып «укый». Тәрбияче сүзнең беренче авазын атарга куша. Балалардан дөрес җавап алгач, бу авазның «тылсымлы»мы-юкмы икәнен билгеләү өчен, башта **[ш]** авазын сузып әйтеп карыйлар **ш-ш-ш**, аннан соң кычкырып әйтәләр. Ләкин «тылсымлы» авазны әйткәндә, авыздан һаваның бик иркен рәвештә чыгуын, аңа бернәрсә дә комачауламавын искә төшерәләр. Тәрбияче тагын бер тапкыр **[ш]** авазын әйтеп карарга куша. «Монда нәрсә комачаулый соң?» дигән сорау куела. Балалар «һава йөрешенә тешләр комачаулый» дигән карарга киләләр. Димәк, **[ш]** авазы «тылсымлы» аваз түгел. Шуннан соң тәрбияче *шар* сүзендәге икенче авазны әйтергә куша. Дөрес җавап алгач **[а]**, бу авазны тикшереп карыйлар һәм аның «тылсымлы» аваз булуына инаналар. Бу авазны әкрен дә, кычкырып та әйтеп карыйлар: сузалар, җырлыйлар һәм һава йөрешенә тоткарлык юклыгын раслыйлар. Ә өченче **[р]** авазын тикшереп карагач, телнең тоткарлык ясавы ачыклана. «Димәк, *шар* сүзендә бер генә «тылсымлы» аваз — **[а]** дигән нәтиҗә ясала.

Сәлам, дустым! ....3
1 нче шөгыль .... 4
2 нче шөгыль....6
3 нче шөгыль....8
4 нче шөгыль....10
5 нче шөгыль....12
6 нчы шөгыль....14
7 нче шөгыль....16
8 нче шөгыль....18
9 нчы шөгыль....20
10 нчы шөгыль....22
11 нче шөгыль....24
12 нче шөгыль....26
13 нче шөгыль....28
14 нче шөгыль....30
15 нче шөгыль....32
16 нчы шөгыль....34
17 нче шөгыль....36
18 нче шөгыль....38
19 нчы шөгыль....40
20 нче шөгыль....42
21 нче шөгыль....44
22 нче шөгыль....45
23 нче шөгыль....47
24 нче шөгыль....49
25 нче шөгыль....51
26 нчы шөгыль....53
27 нче шөгыль....55
28 нче шөгыль....57
29 нчы шөгыль....59
30 нчы шөгыль....61
31 нче шөгыль....62
32 нче шөгыль....64
33 нче шөгыль....66
34 нче шөгыль....68
35 нче шөгыль....70
36 нчы шөгыль....72
37 нче шөгыль....74
38 нче шөгыль....76
39 нчы шөгыль....78
40 нчы шөгыль....79
41 нче шөгыль....80
42 нче шөгыль....82
«Тере модельләр» уены ....84
«Тылсымлы» авазлар турында ....85

*Учебное издание*

**Шаехова Резеда Камильевна**

**Азбука для дошкольников**
**Играем со звуками и словами**

Рабочая тетрадь №1
для детей старшего дошкольного возраста

*(на татарском языке)*

Редакторы *Р. Вафина*
Компьютерда биткә салучысы *Э. Уракова*
Корректоры *Ә. Әхмәдуллина, Н. Габдрахманова*

Оригинал-макеттан басарга кул куелды 25.10.2011.
Форматы 84х108 1/16. Офсет кәгазе.
«Times New Roman» гарнитурасы.
Шартлы басма табагы 6. Тиражы 10000 д. Заказ .

Татарстан Республикасы «ХӘТЕР» нәшрияты.
420111. Казан, Тельман ур., 5.
Хатлар өчен: 420014. Казан, Кремль, а/я 54.
Тел.: (843)264-67-96.

«Татмедиа» ААҖ филиалы —
«Идел-ПРЕСС» полиграфия-нәшрият комплексы.
420066. Казан, Декабристлар ур., 2.